Сырхауханәләр халык белән «дуслаша»

Башка сырхауханәләргә керүгә, кайсы ишеккә барып бәрелергә белми йөрисең, биредә һәр кешене бусагадан ук каршы алалар. Елмаеп исәнләшкән шәфкать туташлары кирәкле табибның нинди кабинетта утыруын, теркәлү узу тәртибен дә әйтеп бирә, олы кешеләрнең аякларына бахилларга кадәр кияргә ярдәм итә. «Дуслык сырхауханәсе»нең төп максаты да кешеләргә уңайлы булсын өчен барлык шартларны тудыру.

4 БИТ

Радик Юльякшин:

«Попугай кебек киенеп, авыз ачып торучы гына түгел мин»

«Дөресен генә әйткәндә, үземне әле дә егермесе тулмаган малай кебек хис итәм. Төс-кыяфәтемә карап, яшемне әйтү кыен. ЮХИДИ хезмәткәрләре еш кына паспортымны сорый, янәсе, машина йөртергә башым яшь әле. Күпләр өчен мин мәктәп укучысы булып калам. Шуңа күрә «Элвин Грей» да – «яшьсез» проект.

7 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Җомга | 13.01.2017 | № 2 (5764)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

КИЛӘЧӘКТӘ ДӘ БЕР КАЗАНДА КАЙНЫЙК!

Кичә «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Андрей Кузьмин журналистларны республикада 2017 елның беренче яртыеллыгына язылу кампаниясе нәтиҗәләре белән таныштырды. Җитәкче китергән мәгълүматлар буенча, «ТАТМЕДИА» басмаларына язылу буенча гомуми тираж («Татарстан почтасы» һәм альтернатив язылу) 257 719 данәне тәшкил итә. Узган елның шушы чоры белән чагыштырганда, күрсәткечләр җиде процентка кимрәк.

Зөһрә САДЫЙКОВА

tatar-inform.ru

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

– 2016 ел икътисади яктан авыр булгач, нәтиҗәләр начаррак булыр дип уйлаган идек. Шулай да алдагы ел күрсәткечләрен саклап кала алдык, – диде ул.

Аның сүзләренә караганда, район һәм шәһәр газеталарына язылу күләме – 174 459, республика газеталарына – 33 786, ә журналларга язылу 49 474 данә.

Күрсәткечләрнең бераз кимүе турында «Татарстан почтасы» идарәсе җитәкчесе урынбасары Светлана Гришина да әйтеп узды.

– 2017 елның беренче яртыеллыгына язылу тиражын саклап калырга дип планлаштырсак та, күрсәткечләр 1,5 процентка кимеде. Бу беренче чиратта, законга кайбер үзгәрешләр кертелү нәтиҗәсендә, «Татнефть» ширкәте гамәлгә куйган «Нефтяные вести», «Хәзинә», «За нефть» кебек басмаларның базардан алынуына бәйле. Ә менә физик затлар арасында укучыларыбыз санын саклап кала алдык. «Татарстан почтасы» язылу кампаниясенә һәрвакыт зур игътибар бирә, чөнки абунә бик зур социаль мәгънәгә ия. Ташламалар системасын да саклап калдык. Газета-журналларга язылган вакытта Бөек Ватан сугышы ветераннарына, беренче һәм икенче төркем инвалидларга 20 процент ташлама ясала. Начар күрүче һәм сукырлар өчен махсус чыгарыла торган басмаларга исә 100 процент ташлама каралган. Социаль әһәмияткә ия булган басмалар исемлегенә «ТАТМЕДИА»ның барлык басмалары да кертелгән, – диде ул.

Күрсәткечләр берникадәр кимесә дә, Татарстан Россиянең иң күп укучы төбәкләренең берсе булып кала бирә. Һәм монда альтернатив абунәнең дә никадәр зур роль башкаруы турында язып узарга кирәк.

– Безнең күпчелек укучыларыбыз газета-журналларга «Татарстан почтасы» аша языла. Ләкин шуның белән беррәттән, альтернатив абунә институтын да үстерәбез. «Россия почтасы»ның тарифлары югары булганлыктан, безнең сафларга кушылырга теләп тә, бәяләрдән бераз куркып калган укучыларыбыз өчен менә дигән вариант бу. Газеталарга бәя артуын тотып калу һәм үз укучыларын саклау максатыннан, безнең филиаллар инде берничә ел альтернатив абунәне үстерә, – диде Андрей Кузьмин.

Аңлатып китик. Альтернатив абунә редакцияләрдә, шәхси эшмәкәрләрнең сәүдә нокталары аша, төрле оешма хезмәткәрләренә, балалар бакчаларына, мәктәпләргә илтеп бирү юлы белән тормышка ашырыла. Шуңа күрә әгәр «Шәһри Казан» газетасын бик алдырырга теләп тә, финанс мөмкинлегегез чикле икән, без сезгә ярдәм йөзеннән, уңайлы булган юлны сайларга ярдәм итәрбез. Алай гына да түгел, почта бүлекләренә барып газетага язылу мөмкинлегегез юк икән, редакциябезгә дә шалтырата аласыз. Без сезгә ярдәмгә килергә һәрчак әзер.

→ **Ахыры 2нче биттә.**

Закон – төн уртасында да закон

Автор фотосы

Законны белмәү җаваплылыктан азат итми. Кызганыч, белә торып та бозучылар бар.

М-7 «Волга» автотрассасының Биектау районы җирлегендә урнашкан «Үзбәк кухнясы» кафесы буфетчысы 2015 елның 25 сентябрендә сыра саткан. Бер караганда, сыра нәрсә инде ул? Ләкин буфетчы кыз сыраны төнге 12дә сатып җибәргән. Кемгә? Рейд үткәргән дәүләт алкоголь инспекциясе хезмәткәрләренә саткан бит, каһәр суккыры. Россиядә кичке сәгать 10нан иртәнге 10га кадәр спиртлы эчемлекләр сату закон нигезендә тыелган.

– Буфетчы эшеннән җибәрелде, – диде кафе хуҗасы Рамил Гайнетдинов.

Тик мәсьәлә чишелмәгән, хәлләр куерып кына киткән әле.

– Канунны бозганнары өчен кафе хуҗасына 50 мең сум штраф салынган. Ул аны 60 көн эчендә түләмәгән. Хәзер инде бу сумма икеләтә арттырылды, – дип аңлатма бирде Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе әйдәүче белгече Альберт Ибәтуллин. – Моннан тыш, кафеның пенсия фондына һәм салым органнарына түләнелмәгән 500 мең сум бурычы да бар.

– Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан салынган 100 мең сум штрафны гына түлисем калды. Калганнарын узган елның уртасында ук түләп бетердем, – ди Рамил Гайнетдинов.

Суд приставлары буш сүзгә генә ышанмый шул, чөнки түләүләрне башкарганлыкка квитанцияләр юк.

– «Үзбәк кухнясы» кафесының 109 мең сумлык милкенә арест салынды, – диде Суд приставлары федераль хезмәтенең Биектау районы бүлекчәсе башкаручы суд приставы Әлфия Дәүләтярова. – Әгәр кафе хуҗасы ун көн эчендә бурычларын капламаса, арест салынган милек сатып җибәреләчәк.

Альберт Ибәтуллин сөйләгәнчә, суд приставлары узган ел Дәүләт алкоголь инспекциясе штрафлары буенча 700дән артык башкарма эш кабул итеп алган булган. Шушы юнәлештәге ун миллион сум штрафның 3,5 миллион сумын гына кайтарып аласы калган. Спиртлы эчемлекләр сату турындагы законны бозганы өчен салынган штраф бурычлары аркасында, 12 кешегә чит илләргә чыгу хокукы чикләнгән, 110 транспорт чарасына теркәү үткәрү туктатылган.

– Суд приставлары Дәүләт алкоголь инспекциясе хезмәткәрләре белән берлектә уртак рейдларны даими оештыра, – дип кисәтте Альберт Ибәтуллин.

Кичә шундый рейдта без журналистлар да катнаштык. Салымнарны һәм штрафларны суд приставлары «якаңнан» эләктереп алганчы башкаруың мең хәерлерәк.

Дамир БӘДРИЕВ.

«Татфондбанк»та кертемнәре булганнарга банк агентлар аша акчаларын кайтару дәвам итә. «Интех-Банк»та акчалары булган затлар да 12 гыйнвардан «Саклык банкы», ВТБ 24 һәм «АК БАРС» банклары аша иминият кертемнәрен алырга хокуклы.

Кертемнәр кайтарыла

Кертемчеләргә акчалар 100 процент кайтарыла, әмма сумма 1 миллион 400 мең сумнан артмый. Клиентка кайсы банкка мөрәҗәгать итәргә кирәклеге фамилияләрнең баш хәрефләре буенча бүленгән.

Шулай ук «Татфондбанк»ны торгызу өчен җаваплы санатор эзләү эшләре дә дәвам итә. Банкны санацияләү турында карар кабул ителгән очракта, республика хөкүмәте финанс ярдәме күрсәтергә әзер, дип хәбәр итә «Прайм» икътисади мәгълүмат агентлыгы. «Әгәр санатор ачыкланса, төрле яклап ярдәм итәргә әзербез. Бу өлкәдә нинди дә булса ярдәм күрсәтү мөмкинлекләребез бар. Без моның бик мөһим проект икәнен аңлыйбыз», – дигән Президент Рөстәм Миңнеханов.

Банк капиталына кредиторлар таләпләрен конвертацияләү процедурасы турында сөйләшүләр дә алып барыла. Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, анда депозитларын тоткан компанияләр бар. Әгәр санатор пайда булса, алар депозитларын капиталлаштырсын өчен шушы компанияләр белән сөйләшүләр алып барылачак. Хәзер барысы да Үзәк Банк нинди карар кабул итүеннән тора.

*Иминият акчаларын алу тәртибе Иминият кертемнәре агентлыгының www.asv.org.ru сайтында урнаштырылган. Тулырак мәгълүматны банк-агентларның «кайнар линия»ләренә һәм агентлыкның **8-800-200-08-05** номерына шалтыратып та белергә була.*

Бәйрәм белән!

13 гыйнвар – Россия матбугаты көне. Шул уңайдан матбугат хезмәткәрләрен Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин котлады.

«Киң җәмәгатьчелектә абруй казанган һәм ышаныч яулаган республика массакүләм мәгълүмат чаралары бүген катлаулы шартларда эшли. Интернет-коммуникацияләрнең актив үсеше, төрле мәгълүмат ресурсларыннан, ә кайчакта ялган хәбәрләрдән иркен файдалану мөмкинлеге халыкта сыйфатлы журналистикага зур ихтыяҗ тудырды. Массакүләм мәгълүмат чараларының актив җаваплы позициясе, бәйсез һәм кыю публицистика – илебездә демократияне ныгыту һәм җәмгыятьтә ышанычны арттыру өчен зарур шарт. Хәзерге вакытта журналист вакыйгаларның хронологик язмасын алып бару белән генә чикләнмичә, җәмәгатьчелектә фикер тудырырга, гражданнарның әхлакый һәм рухи юнәлешләренә этәргеч бирергә, агарту һәм берләштерү ролен үтәргә тиеш.

Хөрмәтле журналистлар, газета һәм журнал редакцияләре хезмәткәрләре, полиграфистлар, ветераннар һәм яшь каләм ияләре! Сезнең һөнәрегез югары шәхси һәм профессиональ сыйфатларны: намуслы, белемле булуны, мөстәкыйль фикерләү, вакыйгаларга тирән анализ ясый белүне, сүз кадерен белүне, эфирда яисә вакытлы матбугат битләрендә әйтелгән һәр сүз өчен социаль җаваплылык тоюны таләп итә. Җәмгыятьнең объектив мәгълүматлы булуы, журналист сүзенең янәрышка, кешелеклелеккә, гаделлеккә хезмәт итүе нәкъ менә сезнең белемегезгә һәм һөнәри осталыгызга бәйле.

Кадерле дуслар! Бу бәйрәм көнендә сезнең барыгызга да нәтиҗәле хезмәтегез, югары һөнәри осталыгыгыз, үз эшегезгә тугрылыклы булганыгыз өчен рәхмәтемне белдерәм. Каләмегез үткен булсын! Яңа иҗади уңышлар, күтәренке рух, бәхет һәм исәнлек-саулык телим», – диелгән Дәүләт Советы рәисе котлавында.

Киләчәктә дә бер казанда кайныйк!

→ Ахыры. Башы 1нче биттә.

Шунысын искәртеп үтик, быел язылу кампаниясе чорында берничә акция оештырылды. #АбунәБүләкИт2017 проекты вакытында «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең меңләп газета-журналлары яздырылды. Әлеге акция вакытында безнең «Шәһри Казан» газетасы да читтә калмады. Республикабызның мөхтәрәм кешеләре ярдәме белән, газетабыз үрнәк гаиләләргә, балалар һәм картлар йортларына барып ирешә. «Шәһри Казан»ны башкаларга яздырып бүләк итүчеләр арасында министрлар, Дәүләт Думасы һәм Дәүләт Советы депутатлары, эшмәкәрләр, артистлар һәм башкалар да бар иде.

«Абунә бүләк ит» хәйрия акциясе – алдагы язылу кампанияләре чорында да дәвам иттерелергә тиешле бик матур гадәт. Күп очракта Интернет челтәреннән башка дөньяны белмәгән замана яшьләренә, җитәкчеләргә газета-журналларга язылу чоры барганлыкын искә төшерү өчен генә булса да дәвам иттерелергә тиеш ул. Шушы акция кысаларында, никадәрле социаль учреждениеләргә, керемнәре аз булган гаиләләргә, ветераннарга матбугат чарасы бүләк ителде.

Хөрмәтле укучыларыбыз, «Шәһри Казан» газетасы әлеге яртыеллыкка яздыру чорында сезгә тагын да якынайды. Язылу чорына нәтиҗә ясасак, безнең газета – берничә күрсәткечләр буенча лидерлар рәтендә. Почта аша язылып укучылар санын арттыру, ваклап сату, альтернатив абунәне үстерү буенча да алдынгы урынны били. Болар – сезнең безгә ышанычыгыз нәтиҗәсе. Безнең белән бер «казан»да кайнаганыгыз, безгә тугры калганыгыз яки сафларыбызга яңа гына кушылганыгыз өчен зур рәхмәт сезгә! Алга таба да бергә һәм бердәм булыйк!

Армиягә барсаң, эшкә аптырамыйсың

2016 елгы көзге чакырылыш барышында хәрби хезмәткә 152 мең кеше чакырылган.

Бу хакта Россия Кораллы көчләр генштабының баш оештыру-мобилизацияләү идарәсе җитәкчесе, генерал-полковник Василий Тошканкуров хәбәр итте, дип яза «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы. Ул чакырылыш кампаниясен оештыруда Татарстанны лидерлар рәтендә атады.

Хәрби хезмәткә чакырылучыларның шактые – югары белемле. Әгәр моннан 15 ел элек хәрби хезмәткә алынучыларның 3 проценты гына югары белемле булган булса, хәзер исә бу күрсәткеч 19 процентның артып китә икән. Татарстан монда да лидерлар исемлегендә. 2016 елгы көзге чакырылыш егетләренең 26,5 проценты югары уку йортларын тәмамлаган, ярытысыннан күбрәге – урта-махсус, ә калганнары – гомуми урта белемлеләр.

– Закон буенча – аларга сайлау мөмкинлеге бирелә – бер ел хезмәт итәргә дә, ике ел контракт буенча хезмәт итәргә дә мөмкин. Югары белемле хәрбиләрне, кагыйдә буларак, без укыту берләшмәләренә, хәрби частьларга белгечләр әзерләргә, ә бик сәләтлеләрен фәнни роталарга җибәрәбез, – дип сөйләде Василий Тошканкуров.

Татарстанда хәрби хезмәттән качып йөрүчеләр юк дәрәҗәсендә, шуңа да ул студентлар белән эшләү тәҗрибәсен уртаклашуны сорады.

– Югары уку йортлары студентларын хәрби хезмәтне үтәргә үгетләү өчен, без вуз ректорларын районның хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре составына керттек. Ә ректорлар советы рәисе – КФУ ректоры Илшат Гафуров – республика чакыру комиссиясе составында, – дип аңлатты премьер-министр урынбасары Алексей Песошин.

Моннан тыш, республиканың һәр университетына, институтына хәрби комиссариаттан бер куратор беркетелгән. Алар хәрби хезмәткә әзерләү, аны узу буенча аңлату эшләре алып баралар. Укыту корпусларында, тулай торакларда «Призывник почмагы» эшләп куелган. Чыгарылыш курс студенты медкомиссия узу өчен военкоматка килергә чакыру кәгазен дә үз деканатында ала, дип кайбер детальләргә тукталды республиканың вице-премьеры.

Булачак солдатларның сәламәтлеге исә студентлар сырхауханәләрендә тикшерелеп тора. Аларның күбесе спорт белән шөгыльләнә. Моннан тыш, Бөек Ватан сугышы ветераннары, хәрби хезмәтне узып кайткан элеккеге студентлар белән очрашулар да үзенең нәтиҗәсен бирми калмый. Шунысы кызык, егетләрнең күбесе контракт буенча хезмәт итәргә кала икән.

Армиядә хезмәт итеп чыныгып кайткан яшь белгечне эшкә дә теләп алалар.

– Безнең Казан авиация заводы, «КАМАЗ», Оргсинтез, Түбәнкаманефтехим кебек сәнәгать гигантлары хәрби хезмәт срогын тутырып кайткан гражданнар арасында махсус эш алып бара, предприятиеләрдә аларга эш урыннары тәкъдим итә, – дип басым ясады Алексей Песошин.

Бәйрәм көннәре – саннарда

✓ Кышкы каникул көннәрендә Казанда 379 бала туган. Аларның 178е – малайлар, 201е – кызлар. 2017 елның беренче сабые шәһәрнең 16нчы хастаханәсе каршындагы бала тудыру йортында туган.

✓ Исерек килеш машина белән идарә иткән 95 кеше тоткарланган. Шуларның 33е Яңа ел төнендә руль артына утырган.

✓ Чыршы белән законсыз сату иткән өчен 152 кеше штрафка тартылган.

✓ 184 җинаять эшләнгән, узган ел белән чагыштырганда, бу – 78гә кимрәк.

✓ 700 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән.

✓ 17 янгын чыккан, өч кеше зыян күргән.

✓ Ашыгыч ярдәмне 58 кеше – инфаркт куркынычы янаганга, 200 кеше кан басымы уйнаганга чакырткан. 3559 кешегә ОРВИ диагнозы куелган. Өч кеше суррогат аракы эчеп агуланган. 2867 кеше травмпунктка мөрәҗәгать иткән.

Милләт рухын туплаган китап

Татарстан китап нәшриятында язучы, тәрҗемәче Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге» китабының беренче томы дөнья күрде. Ул өч томнан торачак.

– Бу – 2016 елда бездә басылган иң соңгы китапларның берсе. Ул тарих, татар дөньясы өчен зур вакыйга. Сүзлекнең тиражы әлегә 3000 данә. Китапның 1700 данәсе республика китапханәләренә таратылачак. Аны Бауман урамы, 19нчы, 29нчы йортларда, Татар китап нәшриятының «Идел-пресс» үзәгендәге китап кибетендә, «Таткнига.ру» сайтыннан сатып алып була, – диде Татарстан китап нәшрияты генераль директоры Илдар Сәгъдәтшин.

Саллы материаллар тупланган, зәвык белән эшләнгән китапның бәясе дә очсыз түгел. Кибетләрдә аны 1500 сумга сатачаклар. Ләкин Адлер Тимергалинның гомер буе җыйган хезмәте бу бәяне аклый, ди китапны туплаучылар. 2017 һәм 2018 елларда китапның икенче һәм өченче томы дөнья күрәчәк. Якын киләчәктә китапның электрон вариантын да укып булачак. Аны шул ук «Таткнига.ру» сайтыннан очсыз бәягә сатып алырга мөмкин. Китапның тышлыгын Адлер әфәнденең кызы – рәссам Алсу Тимергалина бизәгән.

– Адлерның бер китабы дөнья күргән иде инде, ул шулкадәр тәмле булды, кече телгә генә тиеп калды. «Миллият сүзлеге»н аңлатмалы сүзлек дип әйтәбез, ләкин ул – күпкә зуррак хезмәт. Андагы кайбер мәгълүматларны аерым бер китапчык булларак чыгарып була. Бу җыентык – берничә институт хезмәтенә тиң эш. Китапны туплаганда төп максатыбыз авторлыкны саклап калу иде, – диде тарих фәннәре докторы Гамирҗан Дәүләтшин.

Язучы, Тукай исемендәге Дәүләт премиясе иясе Газинур Морат исә: «Сүзлекне барлык катлам кешеләренә укып чыгарга кирәк», – ди.

– Нинди һөнәр иясе булуга карамастан, кеше аның өч томын да укып чыккан икән, ул инде төрки татар тарихы белән шактый гына танышып чыккан булачак. Андый кеше инде тарих битләреннән сукыр кеше кебек адашып йөрмәс, – диде ул.

Алисә САБИРОВА.

100 яшьлек Вилдан Гарипов вафат

Лаеш районы, Имәнкискә авылында яшәгән 100 яшьлек Вилдан бабай Гариповны кичә җирләгәннәр. Ул авылында мәдәният йорты төзетеп, шунда авылдашлары каршында гармун уйнарга хыялланган иде. 14 декабрьдә шул гозер белән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка да мөрәҗәгать итте.

«Шәһри Казан» газетасының 29 декабрь санында узган елга нәтиҗәләр ясаганда, без Вилдан бабайга да шалтыраттык.

«Быел миңа 1 июльдә 100 яшь тулды. Бик күп котлаулар кабул иттем. Район башлыгы Михаил Афанасьев та, Татарстанның сәламәтлек саклау министры Адел Вафин да килеп тәбрикләделәр. Президентыбыз да килергә тиеш иде дә, килеп кенә җитә алмады. Шулай булса да, башка кешеләр артыннан котлавын да, бүләккә дип диванын да җибәрде. Туган көн Рамазан аена туры килгәнгә, киленем ул көнне авыз ачтырды. Аллага шөкер, күзләрем күрә, зиһенем дә бик яхшы, тамагымнан ризык та үтә. Балаларым үземне күтәреп кенә йөртә. Киленемне безнең бәхеткә Ходай биргән, дим. Тик минә күңелне борчып торган бер генә мәсьәлә бар. Авылыбызның клубы авария хәлендә, бик иске, шунлыктан концертлар да куелмый. Чөнки аңа керә торган түгел – куркыныч. Авылда кафе бар, ә мәдәният йорты юк. Бу хакта Президентыбызга да җиткердем. «Мин үзем гармунда уйныйм, яңаны төзетсәгез, шунда чыгып сыздырыр идем», – дидем. Ул өч ай эчендә төзеп бирергә вәгъдә итте. Менә хәзер шуны көтәбез инде», – дигән иде ул.

Урыны оҗмахта булсын!

Казан шәһәре мэриясе, әнисе
Илһамия Газиз кызы ИСХАКОВАның
вафат булуы сәбәпле, Татарстан Президенты ярдәмчесе, Казан шәһәренең мактаулы гражданины Камил Шамил улы Исхаковның тирән кайгысын уртаклаша.

Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе, әнисе
Илһамия Газиз кызы ИСХАКОВАның
вафат булуы сәбәпле, Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе Камил Шамил улы Исхаковның авыр кайгысын ихластан уртаклаша.

Тирән кайгы ачысын туганнарыгыз һәм якыннарыгыз белән бергә без дә бүлешәбез.

«Казан нуры» мәчете мөтәвәллияте, сөекле әнисе
Илһамия Газиз кызы ИСХАКОВАның
вафат булуы сәбәпле, Мөхтәрият Советы рәисе Камил Шамил улы Исхаковның һәм туганнарының авыр кайгысын уртаклаша.

Сырхауханәләр халык белән «дуслаша»

Татарстан Президентының социаль сораулар буенча ярдәмчесе Ләйлә Фазлыева, Татарстанның сәламәтлек саклау министры Адел Вафин һәм Казан шәһәренең Башкарма комитеты җитәкчесе Денис Калинкин 18нче шәһәр сырхауханәсе эш тәртибе белән танышты. Әлеге бинада күптән түгел капиталь ремонт эшләре тәмамланган иде. Хәзер ул «Дуслык сырхауханәсе» программасы өчен пилот мәйданчык булып тора.

Алисә САБИРОВА

Шамил Абдюшев фотосы

Башка сырхауханәләргә кергәч, кайсы ишеккә барып бәрелергә белми йөрисең, биредә һәр кешене бусагадан ук каршы алалар. Елмаеп исәнләшкән шәфкать туташлары кирәкле табибның нинди кабинетта утыруын, теркәлү узу тәртибен дә әйтеп бирә, олы кешеләрнең аякларына бахилларга кадәр кияргә ярдәм итә. «Дуслык сырхауханәсе»нең төп максаты да кешеләргә уңайлы булсын өчен барлык шартларны тудыру.

– Авырулар сырхауханәгә килүгә үк матур, чиста, ә иң мөһиме – белгечләр яхшы мөгамәләдә булган мохиткә эләгә. Табибка язылу терминалларында шәфкать туташлары кизү тора. Табиб бер авыруны хәзер 12-15 минут кабул итә. Документлар белән бәйле эшнең бер өлешен шәфкать туташлары башкара, шуңа да табиб авыруга күбрәк игътибар бирә. Участок табибларының исә эш вакыты 7 сәгать 40 минут дәвам итә. Бу исә табибка эләгергә мөмкин булганнарның санын 30 процентка арттыра. Чиратта исә кеше ун минуттан да озаграк торырга тиеш түгел. «Дуслык сырхауханәсе» программасы бездә июль аеннан гамәлдә. Халык та, табиблар да канәгать. Бу ике якның да хәлен җиңеләйтте, – дип таныштырды сырхауханәдә булган үзгәрешләр белән аның баш табибы Резидә Мансурова.

Элек медицина хезмәтләре, табибларның кайсы бүлмәдә урнашканы турында бары вак хәрефләр белән язылган тактадан белеп булган. Хәзер исә юл күрсәткечләр, зур хәрефләр белән, диварларга ук беркетелгән. Бу исә кирәкмәгән табибка чират торуны 20 процентка киметкән. Авырулар табибны өйгә чакыру очраклары да еш күренеш. 18нче сырхауханәдә моның өчен хәзер махсус фельдшер бригадалары эшли. Алдан чиратка язылмаган авырулар кизү торучы табибта тикшеренә. Хәзер андый авыруларны ике табиб кабул итә. Грипп, салкын тию кебек авырулар яхшы көчәйгән вакытта, кизү торучы табибка башка хезмәттәшләре дә ярдәмгә килә. Сырхауханәдә 67 мең кеше теркәлгән, моңа өстәп әле стоматология, травматология, хатын-кызлар өчен консультация бүлеге дә эшли. Теркәлү бүлеге урынында хәзер ял итү мәйданы. Биредә диваннар, эчә торган су, телевизор, интернет бар. Сырхауханәне төзекләндерү өчен биш миллион сумнан күбрәк акча киткән. Шуларның дүрт миллионы – төзелеш эшләренә, калганнары медицина җиһазларына тотылган.

– Бүген пилот проект Казан, Чаллы, Әлмәт, Яшел Үзән шәһәрләрендә тормышка ашырыла. Яшел Үзәндә ул «Татарстанда яшәүче картасы» белән бергә гамәлгә керде. Якын киләчәктә яңартылган медицина үзәкләре дә «Дуслык сырхауханәсе» программасы буенча эшли башлаячак. Элек электрон чиратка язылганнар да, чиратка басмыйча гына килгәннәр дә бер кабинетка керә иде. Кайвакыт авыруларга үз чиратын 40-50 минут көтәргә туры килә. Хәзер исә чиратка язылмаучыларны дежур табиб кабул итә. «Дуслык сырхауханәсе» ул капиталь ремонт кына түгел, ә авыруларга яхшы мөгамәлә булдыру, халыкка якынаю. Безнең эшкә бары тик авырулар гына бәя бирә ала, алар канәгать икән, димәк, без дә яхшы эшлибез дигән сүз, – диде Адел Вафин.

Табиб кабул итү бүлмәсендә хәзер шәфкать туташы утырмавын да министр уңай бәяләде.

– Өченче кеше булганда, пациент табиб сорауларына җавап бирергә читенсенә. Табиб белән пациент икәүдән-икәү генә эшләгән вакытта, дәвалану нәтиҗәләрәк булачак, – диган фикердә министр.

Дөрес, сырхауханәдә күпме генә үзгәреш булмасын, башкарасы эшләр җитәрлек. Сәламәтлек саклау министры янына да мөрәҗәгатьләре белән авырулар чиратка тезелде. Сырхауханәгә тар белгечләр җитми икән. Министр сүзләренчә, бу проблема республикага гына кагылмый. Шулай да Татарстан бу өлкәдә саллы эш башкара. Хәзер табибларга фатир алу җиңелрәк, хезмәт хаклары арта.

Шулай ук сырхауханәдә «Электрон карта» проекты тормышка ашырыла. Барлык язуларын табиб амбулатор картага түгел, ә шунда тутыра. Кәгазь карталар исә махсус бүлектә саклана.

Адел Вафинга өч авыру: «Әлеге сырхауханәгә, 74нче А автобусыннан кала, бер җәмәгать транспорты да йөрми», – дигән зар белән мөрәҗәгать итте.

– Кайвакыт автобусны 40 минут көтәргә туры килә. Ә 47нче автобус «Комаров» тукталышында төшереп калдыра. Ләкин аннан соң да ун минут җәяү, күпер, баскычлар аша барырга кирәк. Мин инсульт кичердем, йөрәгемә операция булды, аяклар да начар йөри хәзер. Минем кебек пенсионерлар күп бит, барысы да, транспорт юк, дип зарлана. Чат саен банк, даруханә, кибетләр ясыйлар, ә халыкка йөрергә уңайлы булган сырхауханәләр юк, – дип уфтанды Казанда яшәүче Розалия Мифтахова.

Хастаханәдә 70 меңгә якын кеше теркәлгән. Бер медицина үзәге өчен бу бик зур сан. Табиблар эшен җиңеләйтү, халыкка йөрергә уңайлырак булсын өчен, Казанның бу өлешендә тагын бер хастаханә төзеләчәк.

– Рихард Зорге урамы, 103нче йорт адресы буенча өр-яңа диагностик үзәк төзелә. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның өчен төзелә башлаган бина бүлеп бирде. Аның мәйданы ун мең квадрат метр булачак, – диде Денис Калинкин.

Күп кенә авырулар, табиблар язган рецептны аңламыйбыз, дип тә зарлана икән.

– Хәзер авыруларның электрон медицина картасы бар. Кайбер сырхауханәләрдә инде дарулар исемлеге компьютерда бастырып чыгарыла. Киләчәктә бу әйберләр махсус картага теркәләчәк, – диде Денис Калинкин .

Быел «Дуслык сырхауханәсе» программасы барлык медицина учреждениеләренә кертелергә тиеш.

Казан – мәхәббәтле йорт

Татарстан башкаласы 2016 елда балалар туу буенча яңа рекорд куйды. Дөньяга 24 564 бала аваз салды, бу – 2015 елгы күрсәткечтән 501 сабыйга күбрәк.

«Эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә әлеге куанычлы саннарны шәһәрнең ЗАГС идарәсе җитәкчесе вазифасын башкаручы-урынбасар Фәридә Гыйлемханова җиткерде. Әгәр 2010 елда гаиләләрдә туган тәүге балалар 57 процентны тәшкил иткән булса, узган ел икенче һәм өченче бәби алып кайту статистикасы – 55 процент. Ике һәм аннан күбрәк балалы гаиләләргә 2007 елдан башлап дәүләт ярдәме программасы эшли.

– Шактый еллар дәвамында кызларга караганда, малайларның күбрәк тууы күзәтелә. Узган ел, мәсәлән, 12 668 малай дөньяга килде, ә кызлар – 11 896 гына, – диде Фәридә Гыйлемханова. – Татарстан башкаласында 2009 елдан бирле туучылар саны үлүчеләрдән күбрәк. Казанда узган ел үлүчеләр саныннан 11 211 кеше күбрәк туды. Соңгы унбиш ел дәверендә үлем-җитем 13 процентка кимеде.

Казанда 10 862 яңа гаилә теркәлгән, бу – 2015 елгы күрсәткечтән 1633 парга азрак. Гаилә коручыларның 60 проценттан артыгы – бер милләттәгеләр.

– Хәзер 90нчы елгылар гаилә кора. Ул елларда балалар туу аз иде. Казанда узган ел гаилә коручыларның беркадәр кими төшүе – шуның кайтавазы, – дип аңлатты Фәридә Гыйлемханова. – Кызганыч, 4732 гаилә таркалды. Аларның күбесе – бергә биш елдан азрак гомер итүчеләр.

Шәһәрнең ЗАГС идарәсе узган ел «Гаиләне саклап калыйк» проектын гамәлгә куйган. Проектка җәлеп ителгән четерекле хәлдәге 519 гаиләдән 364е психологлар һәм ЗАГС хезмәткәрләре белән очрашулардан соң татулашкан. Аерылышуга дип бирелгән 166 гариза кире алынган, ә 198 гаилә гариза язу уеннан кире кайткан.

Дамир БӘДРИЕВ.

Юл газабы – гүр газабы, дип юкка гына әйтмиләр инде ул. Ә кышкы юл мең мәртәбә михнәтлерәк, аны башына төшкән кеше үзе генә белә. Шуңа да еш кына кары чистартылган асфальт юлдан авыл башына кадәр кайтасың да, машинаңны калдырып, җәяү тәпилисең. Ә менә Балык Бистәсе районы Кече Әшнәк авылында яшәүче танышларыбызның ишек төпләренә кадәр җиңел машина белән кайтып туктадык. Кичә генә буран булуга карамастан, ялт иткән урамнары.

Игелекле Шамил

– Безнең игелекле Шамилебез бар шул, Ходай исәнләген бирсен, – диде каршыларга чыккан Нурания апа. – Менә дүртенче кыш инде авылыбыз юлларын кардан чистартып тора, рәхмәт яугыры…

Элек Кече Әшнәк халкы да юл мәсьәләсендә җәфаны күп күргән. Шул юлсызлык аркасында, авыру янына табиб килеп җитә алмаган чаклар да аз булмаган. Бер елны урамнарга керә алмагач, хәтта мәетне дә зиратка җеназа белән түгел, бата-чума носилка белән озатканнар. Хәзер әнә Шамил Гарәпшин юлларны кардан ачу проблемасын бөтенләй онытттырган.

Кече Әшнәктә туып-үскән Шамил абзый үзе район үзәгендә яши икән. Авылда төп нигездә әтисе белән әнисе, авыру энесе яшәгән. Әнисе гүр иясе булгач, әтисен сигез ай буе карап, хөрмәтләп соңгы юлга озаткан. Хәзер энесе белән бергәләп туган нигезне яшәтер өчен тырышып йөри. Әтиләре – Бөек Ватан сугышы ветераны Фасыйх абзый үзе дә авылның мәртәбәле кешесе булган. Авылда бит абруйны ышаныч белән генә яулап була. Авыл советында эшләгәндә дә, колхоз белән җитәкчелек иткәндә дә ветеран коммунист гозер белән килгән берәүне дә борып чыгармаган. Динебезгә мөнәсәбәт үзгәргәч, авылларында мәчет салдыруда да башлап йөргән, мулла вазифасын да башкарган.

Шамил абыйның исә гомеренең күп өлеше юлда узган, ерак аралардан йөк ташыган. Хатыны Нурия ханым белән бер кыз, бер малай үстергәннәр. Аларның инде хәзер үз гаиләләре. Бүген оныкларга игелек серен өйрәтәсе бар әби белән бабайның.

Авыл халкы үзен шулай мактап сөйләгәч, аның үзен күреп аралашасым килде.

– 2010 елның кышында авылыбыз зур дөньядан аерылып калды. Юлларда буран булганга, кибетләргә товар кайтмый башлады. Авыл халкы тоз-шырпысыз калудан куркып, булганын кырып-себереп алып бетергәч, кибет киштәләре бушап калды. Туган авылыма ярдәм итү теләге шул чакта ук туган иде. Җае гына соңрак табылды, – ди ул.

Чүп булып яткан тимер-томыр өеменнән иске генә ДТ-75 тракторын үз куллары белән җыеп, алдына юл кырдыргыч куюы да шул уен тормышка ашыру өчен була аның. Башта мәчет, зират юлларын кардан чистарта. Аннары барлык урамнарның карын эттереп чыга. Юл да чистара, бала-чагага шуар өчен тау да ясала. Кар яуган саен, авылдашларыннан рәхмәт ява Шамил абыйга.

Минем аны «ах» итеп тыңлавыма гаҗәпләнеп:

– Аптырыйсы юк, һәркем яхшы эштә үрнәк күрсәтергә тиеш. Кешедән ярдәм көтеп утырып булмый бит инде, – диде ул һәм: – Исән булсак, авылны ташламыйбыз име?» – дип, тракторына карап куйды.

Соңгы вакытларда без: «Авыллар бетә, кая карыйлар?» – дип лаф орабыз. Ә менә Шамил абзый, гаепне бүтәннәрдән эзләп баш ватмый гына, туган авылына булыша.

Юллар проблемасы шулай хәл ителсә дә, Кече Әшнәк халкының барысын да борчый торган бер мәсьәлә әле һаман да чишелмичә кала бирә. Йөздән артык хуҗалыгы булган авылның шәфкать туташы юк.Озак еллар авылдашларына көн-төн дими хезмәт күрсәткән ханым үзе дә авырып киткән, операция кичергән. Әлегә аңа эшләргә ярамый икән. Фельдшер-акушерлык пунктының бинасы яңа үзе. Кояш төсендәге түбәсе ерактан ук күренеп тора, тик ишегендә – йозак.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

Әбием нигезе

Җанга якын кеше беркайчан да онытылмый. Әбиемнең арабыздан киткәненә дә алты ел. Аның белән бәйле һәр нәрсә кадерле. Балачагыбыз гөрләп узган нигезенә дә хәзер уң аяктан «бисмилла» әйтеп кенә атлыйбыз. Йортының һәр почмагы, үз кулы белән чиккән, мич кашагасына элеп калдырган сөлгеләре, мендәр япмалары аның җылысын саклый, сагындыра.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Ишегенә йозак салынган бикле йортны ачып керүләре бигрәкләр дә авыр. Хуҗасыз йорт тиз таушала икән. Югыйсә, рәшәткәләрен дә яңарттык, капкаларын да буядык. Язын бакчасына бәрәңгесен, яшелчәсен утыртабыз. Ничек тә йортны җанландырырга, авылга эзне суытмаска тырышабыз. Ә менә кыш көне сирәк кайтыла. Дәү әнием исән чагында тәрәзәдән күзен алмый безне зарыгып көтсә, хәзер нигезе, моңсуланып, кайтучыларны күзли. Ишегалдындагы гөлҗимеш тә, кар катламына түзә алмыйчамы, әллә хуҗасын юксынуданмы, башын түбән игән. Өй каршындагы кыргый алмагач кына төп-төз утыра бирә. Тәрәзәдән төшкән бөтен яктылыкны каплап тора, җимеше дә ачы була дип күпме үгетләдек дәү әнине бу агачны кисәргә. Кистермәде. «Мин исән чакта кагылмагыз, бабаегыз утырткан алмагач, аның истәлеге», – дип әйтә иде. Хәзер бу алмагачны үзебез күз карасыдай саклыйбыз, бабайның гына түгел, әбиемнең дә истәлегенә әйләнде ул.

…Без авылга кайткан көнне ишеп кар яуды. Дәү әнинең йортына илтә торган сукмак та күренми. Бил тиңентен кар көртен ерып, йорт ишеген чак ачтык. Авылда ялгызы гына яшәүчеләргә җиңел түгел, карын көрәүче булмаса, өеннән дә чыга алмый ята мескен карт-коры. Шөкер, авыл халкы ялгыз кешенең хәлен белеп тора, яшьләр өлкәннәрне онытып бетерми. Әнә күршебездә берүзе генә яшәүче Флюра әби, Мансура апа, Саимә апаның да ишегаллары тап-такыр, трактор белән киң итеп ачтырылган. Әбиле өйләргә көнләшеп карыйм. Бу йортлардан яңа пешкән камыр исе килә, Корьән тавышлары ишетелә сыман.

Йорттагы тынлыкны бозарга куркып, әчкә узам. Гадәттәгечә, бер почмакта дәү әнинең бәйли башлаган оекбашлары, йон җепләре, гөнҗәләсе, орчыклары тора. Күзе начар күрсә дә, һәр елны оныкларына, кияүләренә оекбаш бәйләп кидерә иде ул. Атна саен бәлешләрен пешереп каршы ала иде. Акшарланган мичкә күптән якын килүче юк, мич авызында буш табалар гына тора. Җиңелчә онга буялган уклавына да инде тузан кунган. Кеше сәгате туктаган белән, вакыт тукталмый. Уклары арттарак калып йөрсә дә, зур якта сәгать текелди. «Гомер уза, вакыт уза», – дип, минутларны саный диярсең. Кеше гомере санаулы, вакытның кадерен белергә кирәклеген искәртә сыман.

Кар туктарга уйламый. Ява да ява. Безнең бата-чума кергән эзләр дә югала бара. Ничек кирәк алай сарайга үтеп, дәү әнинең көрәкләрен табып алдык. Кара җир чыкканчы тап-такыр итеп тирән сукмак салдык. Ишеп яуган кар да күмеп китә алмас аны, дәү әнием йортына юллар беркайчан ябылмас. Нәсел дәвамчылары – оныклары, балалары булганда, әбием нигезе мәңге сакланыр.

Эльвира МОЗАФФАР.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары



Иҗат дәвам итә

80 ел эчендә Татарстан рәссамнары нинди генә күргәзмәләр уздырмаган да, республика сынлы сәнгатенең дәрәҗәсен нинди генә шәхесләр күтәрмәгән? Бу көннәрдә Татарстан сынлы сәнгать музееның Заманча сәнгать галереясында барган юбилей күргәзмәсе күпләрне уйланырга, Бакый Урманче, Харис Якупов, Лотфулла Фәттахов, Садри Ахун, Әнәс Тумашев, Васил Маликов, Әмир Мәҗитов, Надир Әлмиев, Абрек Абзгильдин, Илдар Ханов, Әхсән Фәсхетдинов кебек инде бакыйлыкка күчкән дистәләрчә мәшһүр кылкаләм осталарына бәйле хатирәләр белән уртаклашырга мәҗбүр итми калмагандыр.

Әменә бүген иҗат мәйданы кемнәр кулында? Соңгы биш елда алар нинди әсәрләр иҗат иткән? Рәссамнарыбызны нәрсә илһамландыра, нинди темалар тынгы бирми, күңел күкләре нинди төсләргә бай, өлкән буынның үкчәсенә басып килерлек яшьләр күренәме – әлбәттә, юбилей күргәзмәсенә килгән тамашачы күңелендәге сораулар моның белән генә дә бетмәгәндер. Шулай икән – анысы бигрәк тә яхшы. Иң мөһиме: битараф кына булмыйк. Хәер, халык хозурына куелган эшләрнең һәрвакыттагыча күргәзмә комитеты тарафыннан бөртекләп сайланып алынганын исәпкә алсак, биредә инде иң лаеклы әсәрләр урын алуын чамалавы кыен түгел. Кайчандыр бер канат астында иҗат иткән рәссамнарның бүгенге көндә берничә иҗат берлегенә бүлгәләнүенә карамастан (Россия Рәссамнар берлегенең Татарстан бүлекчәсе – рәисе Виктор Аршинов, Татарстан Рәссамнары берлеге – Зөфәр Гыймаев, Россия Рәссамнар берлегенең Татарстандагы иҗади бүлеге – Илгизәр Самакаев, Россия Рәссамнар берлегенең Чаллы бүлекчәсе – Факил Гайфетдинов һ.б.), аларның һәркайсы үзен лаеклы күрсәтә алды. Әйтик, Россия Рәссамнар берлегенең Татарстандагы бүлекчәсе, берничә залны биләп, 96 рәссамның 185 эшен тәкъдим итте бу күргәзмәдә. Берлек каршында эшләп килүче Яшь рәссамнарның иҗат бүлекчәсе дә үзен тулы куәтенә күрсәтә алды. Татарстан Рәссамнар берлеге тәкъдим иткән экспозиция дә шактый зур урын биләп торды. 100гә якын рәссамның 174 эшен тәкъдим итте алар. Күргәзмәдә тулы бер династияләрнең калку бирелүе дә куанычлы хәл. Әйтик, әнә Виктор Рогожин, Рада Нигъмәтуллина кызлары Изабелла Рогожина һәм Марина Нигъмәтуллина белән берлектә, 40тан артык сын тәкъдим итте. Аларның шәхси тәкъдимнәр, теләкләр дәфтәренә дә тамашачы: «Йа Хода, ни кадәр гүзәллек! Ничек без шушыны моңа кадәр күрмәгәнбез!» – дип соклануларын белдергәннәр.

– Бу – җыр! Бу – тылсым! Моңа үзебез дә аптырыйбыз. Без халык өчен эшлибез, сыннарыбыз остаханәдә шуның кадәр күп. Тик менә аларны күргәзмәләргә йөртү генә авыр шул, – диләр Изабелла белән Марина.

Гомерләрен сынлы сәнгатькә багышлаган сәнгать әһелләрен юбилей уңаеннан бүләкләү дә матур йола. Сәнгать белгече Розалина Шаһиеваның Россия Рәссамнар берлегенең – алтын, ә рәссамнар Александр Иншаков һәм Михаил Кузнецов – көмеш медальләре белән; халык рәссамнары Искәндәр Рәфыйков, Владимир Поповның, сәнгать үсешенә зур өлеш керткән өчен, Россия Рәссамнар берлеге рәисе Андрей Ковальчук имзалаган Рәхмәт хатлары белән бүләкләнүе юбилейны тагын да мәгънәлерәк итте. Өлкән рәссам – Татарстанның халык рәссамы Валерий Скобеевка да тапшырылды Рәхмәт хаты. Сергей Скоморохов, Мәхмүт Ваһапов, Илдус Сираҗиевлар Россия Рәссамнар берлегенең Дипломнарына лаек булды. Тантана уңаеннан Мәдәният министрлыгы да үз бүләкләрен әзерләгән иде.

Тагын шунысын да әйтергә кирәк: татар графикасының 1931-33 елларда Парижда, Чикагода күрсәтелүе хакында үз вакытында сәнгать белгече Петр Дульский илһамланып язган булган. Хәзер инде офыклар тагын да киңрәк. Рәссамнарның эшләре чит илләрдә куелу бүген инде гадәти күренеш. Көнбатышта, Көнчыгышта, Франциядә, Голландиядә, Финляндиядә, Венгриядә, Гарәп Әмирлекләрендә, Пакистан, Төркия, Кувейтта уңыш белән узган күргәзмәләр аша республикабыз рәссамнары татар дөньясын, милли рухыбызны чит илләргә таныта.

Эстафета елдан-ел Суриков исемендәге Мәскәү сынлы сәнгать институтының Казан филиалы, Фешин исемендәге сәнгать училищесы аша узып, Татарстанның сынлы сәнгать ташкынына ныклап торып яңарыш рухы алып килүче яшьләр кулына күчә бара. Бер үк вакытта элеккеге традицияләргә дә тугры булуларын дәлилли килә алар.

Рәссамнар берлеге тарихында иң беренче күргәзмәнең Яшел Үзәндә узуын беләбез. Узган елның 16 ноябрендә Россия Рәссамнар берлегенең Татарстандагы бүлекчәсенең яшьләр секторы (җитәкчесе Илнур Сираҗиев), моннан 80 ел элек булган прецедентны кабатлап, янә Яшел Үзәндә күргәзмә ачты. Ул көнне экспозициягә куелган барлык эшләр, җуелмас хәтер символы булып, Яшел Үзән галереясына бүләк ителде. Бер сүз белән, рәссамнарның иҗат эпопеясы дәвам итә.

Халыкара форумда – беренче

«Булырлык булса, тегәрҗеп белән дә тартып китереп була, китәсене аркан белән тартсаң да юк», – дип юкка гына әйтмиләр. Казанның 1нче балалар сәнгать мәктәбенең өлкәннәр төркемендә рәсем дәресләре укытучысы Айрат Шәйдуллин да әле күптән түгел халыкара форумда, бер дә уйламаганда, «Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Алтын Витязь» призына лаек булды.

Моңа кадәр 24 ел буена янгын сүндерү тармагында хезмәт иткән запастагы подполковникка призны Мәскәүдә тапшырдылар. Укытучы-янгын... Ничектер очы-очка ялганмыймы? Мантыйк шунда ки, кайда эшләвенә карамастан, Айрат Шәйдуллин – гомер буе рәсем сәнгатенә гашыйк кеше. Екатеринбургта Росия Эчке эшләр министрлыгының янгын-техник училищесында янгынга каршы сак техникы белгечләре алганчы ук Лениногорск педагогия училищесының худграфын тәмамлаган кеше ул. 2003-2008 елларда читтән торып Чаллы дәүләт педагогика институтының худграфын да юкка гына тәмамламый инде Айрат. Аның эшләрен шәһәр, республика, төбәк күргәзмәләрендә күрсәң дә гаҗәпләнәсе юк. Күптән түгел Татарстан Рәссамнар берлегенә кабул иттеләр аны. Узган ел «Арт-Сабантуй» күргәзмә-бәйгесендә катнашып икенче премия алуында да очраклык юк иде.

Мәскәүдә алган призга килсәк, аңа ул 1995-2015 елларда Казанда янгын сагы идарәсендә хезмәт иткән чорда музейда ясаган «Янгын сагы тарихы» һәм «Янгын-гамәли спорты» дип аталган дивар бизәмнәре өчен лаек була.

– Соңгы вакытта портретлар ясау белән мавыгып киттем. Милли мотивлар күңелемә бик якын, – ди рәссам.

Сәхифәне **Расиха ФӘИЗОВА** әзерләде.

Радик Юльякшин:

«Попугай кебек киенеп, авыз ачып торучы гына түгел мин»

Эстрадада «кассалы артист» дигән төшенчә бар. Концертына билетлар тиз арада сатылып бетә торган, тамашалары аншлаг белән уза торган җырчыларны шулай атыйлар. Андый йолдызлар татар эстрадасының күк гөмбәзендә бармак белән генә санарлык. Шуларның берсе – Радик Юльякшин, ягъни Элвин Грей.

– Радик, «Элвин Грейдан татар милләтенә файда юк», – дигән фикерләр яңгырады. Бу хакта нәрсә әйтерсең?

– Бу турыда беренче ишетүем. Файда китерә аламмы, юкмы – тамашачы хәл итәр, ә мин моннан соң да тырышып хезмәт куярмын. Тәнкыйть бар икән, димәк, иҗатымны күзәтәләр. Ә менә эшләп, эшләп тә сүз әйтмәсәләр, кайгыга салыр иде.

– Аншлаг белән узган концертларыңның сере нәрсәдә?

– Монда бернинди дә сер юк. Минем хакта коллегаларым нинди фикер йөрткәнен дә беләм. Яңасе, кайдандыр килеп чыктым да, бик җиңел генә елына 300 концерт куеп йөрим. Мине йолдыз итүгә продюсерым миллионнар сарыф иткән, Мәскәү музыкантларыннан җырлар, аранжировкалар ясаткан да, җырчы иткән, ә мин, попугай кебек киенеп, авыз ачып кына йөрим икән.

Эстрадада «кабыныр» алдыннан, биш ел буе Мәскәүдә студиядә бикләнеп, җырлар иҗат иттем. Россия шоу бизнесы, аранжировка ясаучылар, композиторлар, җырчылар белән таныштым. Һәм бу аралашулардан мин, губка кебек, бары тик кирәклесен, файдалысын сеңдерә бардым.

Кыскасы, аншлаглы концертлар ул – иҗатым һәм үз өстемдә биш ел ярым эшләүнең нәтиҗәсе.

– «Элвин Грей» проектында сәхнәгә чын яшеңнән күпкә бәләкәйрәк образда чыгасың. Тормышка карашың формалашкан кеше буларак, әле дә 15 яшьлек булып кылану авырга туры килмиме?

– Дөресен генә әйткәндә, үземне әле дә егермее тулмаган малай кебек хис итәм. Төс-кыяфәтемә карап, яшемне әйтү кыен. ЮХИДИ хезмәткәрләре еш кына паспортымны сорый, яңасе, машина йөртергә башым яшь әле. Күпләр өчен мин мәктәп укучысы булып калам. Шуңа күрә, «Элвин Грей» да – «яшьсез» проект. Бер җирдә дә минем чын яшемне әйтмибез.

– Дуэтларыңа да тукталып китәсем килә. Кайсын гына алма – җырлар халыкка яхшы таныш, хитка әверелә. Альбина Хәкимова белән башкарган «Ашкын, гомер»дән башлап, әле күптән түгел Гүзәл Уразова белән яздырган «Красивая, хороший»-га кадәр...

– Дуэтларга карашым җитди. Һәрчак продюсерым белән киңәшләшәм. Теләсә кем белән дуэт яздырып булмый, тембрлар буенча туры килү дә бик мөһим. Дуэтларны беркайчан да коммерция нигезендә башкармыйм. Кем миңа кадерле, кемнең иҗаты якын һәм күңелемә кергән – бары тик шуның белән генә җырлаячакмын. Аларның хитка әверелүенең дә сере шундадыр. Теләгән бар кеше белән дә дуэт җырлап чыктым. Ә, юк! Бер кеше бар икән. Аныцы шулай ук кызыклы дуэт булырга тиеш. Кем белән икәнен әлегә сер итеп калдырам, әмма тиздән беләчәксез.

– Эстрадада продюсерсыз да эшләп буламы?

– Эшләргә була, әмма уңышлы булыр микән?! Яныңда һәрвакыт хаталарыңны күрүче, тәнкыйтьләп торучы кеше булырга тиеш. Ул – остаз да, укытучы да, беркайчан да ялагайланмый, икейөзлелек белән шөгыльләнми. Андый кеше булмаса, үсеш тә юк дигән сүз. Ә бары тик: сүлпәнлек, онытылу, бәла...

– Гастрольләрдә әниең гел синең белән...

– Ул минем фәрештәм, талисманым. Ул киемемне дә үтүкләп бирә, чәйне дә кайнарлатып тора. Аңа бар эшемне дә тулысынча ышанып тапшыра алам. Командамда әнием белән бергә 11 кеше. Гастрольләрдә ул минем генә түгел, ә бөтен коллективның әнисе. Аның белән барыбызга да җылы һәм тыныч.

– Костюмнарың хакында да сөйләшик әле. Аларның дизайнын стилистлар уйлап табамы? Кайбер костюмнарың, дөресен генә әйткәндә, бигрәк сәер...

– Минемчә, сәхнә киеме ул – үзе бер мәдәният. Урамга да, дискотекага да, кунакка да, зур сәхнәдәге концертка да бер кием киеп булмый. Сәхнә киемен яңартып тору да мөһим. Биш ел буена бер күлмәк киеп йөргән җырчылар бар. Бу кызык та, кызганыч та. Киемне үзең түгел, ә стилистлар, дизайнерлар белән берлектә уйлап чыгарырга тиешсең. Синә матур булып торган киемнең сәхнәдә бөтенләй «югалуы» да бар.

Әйе, килешәм, кайбер костюмнарым бигрәк сәер. Дизайнерлар тәкъдим иткәч, моны ничек киярмен дип, үзем дә аптырап куям. Әле киләчәктә тегеләчәкләре бөтенләй «телсез» калдырыр (көлә). Мәсәлән, кемдер мин кигән плащларны аңлап бетерми. Сүз дә юк, классик кием матур, әмма бөтен кеше дә сәхнәгә костюм киеп, галстук тагып чыкса, кызыгы каламы соң?

Костюм белән генә эш бетми. Тулысынча образ тудыру мөһим. Костюмга килешле итеп прическа эшлисең. Шоу-бизнесның нигезе булып иң тәүдә образ тора да инде.

Гомумән, җырчы шоу-бизнеста башкаручы гына булып кала алмый. Ул актер да. Яхшы шоу өчен имиджны үзгәртергә кирәк дигән караштамын. Мәсәлән, Иван Дорн сәхнәгә үкчәле аяк киеме киеп чыкты. Әлбәттә, бу нормаль күренеш түгел, әмма матур шоу.

– Тормышта син нинди?

– Шат күңелле, шаян булырга тырышам. Житди булуны таләп иткән чаклар да бар.Ул, миңа калса, тәрбиядән тора. Әни миңа дөрес тәрбия бирде. Аның алдында баш иям.

Әңгәмәдәш –
Азалия ИСМӘГЫЙЛЕВА.

Күңеле – көйләр дәрьясы

6нчы сыйныфның пионер отряды сәхнәләштерелгән җыр конкурсына әзерләнә. Шигыре әзер, көе генә юк. Шулчак отрядның иң актив пионеры Эльмира: «Үзем язып карыйммы соң?» – дигәч, барысы да җиңел сулап куя.

Гел «5»кә генә укучы, җәмәгать эшләрендә башлап йөрүче терекөмеш кебек кыз буш сүз сөйли торганнардан түгел. Әйттеме – эшли. Ләкин сыйныфташларын бәладән коткарыр өчен әйтелгән бу сүз хакына шактый тырышырга туры килә кызга. Бу инде кемдер язганны уйнау гына түгел. Күңелендәге көйне эзләп, аз утырмый кыз. Һәм, ниһаять, бөтен сыйныф белән көткән җыр туа. Алай гына да түгел, Әлмәт шәһәренең 15нче мәктәбе укучысы язган бу җыр әлеге конкурста җиңү яулый!

Тәүге уңыш белән канатланган кызның күңеленә җыр дигән тылсым гомерлеккә кереп урнаша. Һөнәр сайлар вакыт җиткәч тә, бүтәннәр шикелле «Кем булырга икән?» дип озак баш ватмый Эльмира. Документларын Лениногорскиның музыка педагогия училищесына илтеп бирә.

Андагы талантлы остазлар Эльмирага моң иленә илтүче серләрне ачалар, сәнгатькә, иҗатка җитди карарга өйрәтәләр. Училищеда укыган чакта ук инде Эльмира тугыз җыр, бернечә музыкаль пьеса иҗат итә, төрле конкурсларда катнаша.

Эльмираның җыр сәнгатенә тартылуы нәселдән килә. Аның ике әбисе дә, Бөек Ватан сугышы ветераны бабасы да җырга гашыйклар. Әнисе дә, эне-сеңелләре белән бергәләп кулына гармун алса, гаиләдә зур концерт башлана. Халык җырларының моңаһәңнәре кызның нечкә күңелен дә кузгатмый калмый. «Җырлы балачак – иң күңелле чак» икәнен аңлаган дипломлы яшь белгеч Чаллының 14нче мәктәбендә музыка укыта башлагач та үз укучыларының балачакларын җыр белән бизәргә тырыша. Ә мәктәптә үз эшен, балаларны яраткан кешегә мәйдан киң. Ул баштаняк сәнгать дөньясына чума. 25 яшендә генә булуга карамастан, «Өлкән укытучы» исемен ала, «Кама таңнары» ансамблендә җырлый. Ә инде үзе әни булгач, балалар бакчасы белән тыгыз элемтәдә торып иҗат итә башлый, нәниләр белән эшли.

Аның җырлары ике яшьлек сабыйлардан башлап, ак яулыклы әбиләр күңеленә дә хуш килә. Аның җырларының авторлары да төрле яшьтә, төрле һөнәр ияләре. Ул хәтта мәктәп укучылары язган шигырьләрне дә көйле итә. Әлмәт нефтьчеләр шәһәре булгангамы, 1997 елда Эльмира Гыйльфанова да һөнәрен алмаштыра: икенче белем алып, нефтьче-инженер булып китә, ләкин җыр-моңнан, иҗаттан, сәнгатьтән аерылмый. Киресенчә, темалар арта. Балаларга атап язылган «Тавык белән чебиләр», «Матуркай», «Яз», «Каен җиләге» кебек җырлар янына «Кайтсаң икән», «Көл, күңелкәй», «Каеннар юллар буенда», «Аңлар идең» кебекләре өстәлә. Бүген Эльмира Гыйльфанованың күп кенә җырлары төрле җыентыкларга кергән, аларны җырчылар да, ансамбльләр дә яратып башкара. Ә Әлмәттә бер генә бәйрәм, бер генә кичә дә аның җырларыннан башка узмый. Эльмира Шәймәрданова–Гыйльфанованың үз башкаручысын һәм үз тыңлаучысын тапкан юлдан артык җыры бар. Шулай да: «Иң шәп җырым әле язылмаган, ул күңелемдә, аны эзләп табасым бар», – ди Эльмира ханым. Декабрьдә ул 50 яшьлек юбилеен каршылады. Бу яшьтә һәркем үткәннәрен, эшләгән эшләрен барлый. Эльмира да гомер буе иҗат иткән җырларын туплап, аларны гаилә альбомындагы фотосурәтләр белән баетып, «Души прекрасные порывы...» дип аталган саллы гына китап әзерләгән. «Үземә бүләк», – ди ул, тыйнак кына елмаеп. Ноталары белән йөздән артык җыр кергән әлеге җыентык – һәммәбезгә бүләк.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Аксубайлылар үзләрен Казанда күрсәтте

Татарстанның «ак төбәге»ннән килгән кадерле кунакларын Казаныбыз ак карлардан келәм җәеп каршы алды. Милләтебезгә, халкыбызга тугры егет-кызлар үстереп биргән Аксубай районы халкын башкалабыз шулай зурлады.

Районыбызның гасырлар буена җыелып килгән бай тарихы, республикабызда тоткан үз урыны бар. Тарихы да бик еракларга, XVII гасырларга ук барып тоташа. Гасырлар язган тарих китабын ачуга – Хәсән Туфан, Газиз Кашапов, Михаил Мулеев, Петр Захаров, Хөсәен Вәлиәхмәтов, Илгиз Зәйниев, Нәбирә Гыйматдинова һ.б. танылган язучыларыбызның каләм чарлаган тавышлары ишетелә.

Мәдәниятле, белемле, динле, һәрчак яңа үрләр яуларга әзер булган тырыш халкым Халыклар дуслыгы йортында якташларын җыйды. Кышкы салкын көндә туган як җылысын алар һәммәбезгә дә өләшеп, күңелле бәйрәм кичәсе оештырган иде. Әлеге очрашу кичәсен якташларыбыз – күп еллар дәвамында Камал театры сәхнәсендә берсеннән-берсе матур рольләре белән тамашачы күңелен әсир иткән Алсу Каюмова һәм күп кызларның тән йокыларын качырган Рүзәл Әхмәдиев алып барды. Кичәне районыбыз башлыгы Камил Гыйльманов һәм шулай ук әлеге очрашуны оештыруда башлап йөргән якташларыбыз – мәдәният министры урынбасары Гүзәл Шәрипова һәм «Аксубай якташлар җәмгыяте» президенты Хөсәен Вәлиәхмәтов башлап җибәрделәр. Талантлы аксубайлылар – «Беляев йолдызлары» проектының җитәкчесе Мартынова Наилә, танылган язучы, публицист, галим Әнвәр Хәйринең кызы Айгөл Хәйри, М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры җырчысы Денис Ханбаба, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле җырчысы Зөлфәт Сөләйманов, Алим Идиятуллин һ.б. моңлы сандугачларыбызның җырларын тыңлап горурланып утырдык. Аксубай районының чуаш фольклор ансамбленең чыгышлары районыбызда яшәүче өч милләт: татар, рус, чуваш халыкларының дуслыгын тагын бер кат ассызыклап үтте. Тамаша берсеннән-берсе матур номерлар белән дәвам итте. Алсу Каюмова белән Илдус Габдрахманов «Диләфрүз – Remake» спектакленнән өзек күрсәтте. «Әкият» курчак театрының баш режиссеры Илдус Зиннуров исә курчаклары белән килгән иде.

Кайсы өлкәне генә алсаң да, барысында диярлек аксубайлылар хезмәт куя, санап бетерерлек түгел, ләкин шулай да тырышып карыйм: язучы, публицист Роза Туфитуллова, «Идел» журналы баш мөхәррире Радик Сабиров, «Шәһри Казан» газетасы баш мөхәррире Гөлнара Сабирова, «Зузәйнефть» оешмасы генераль директоры, Дәүләт Советы депутаты Шамил Яһудин, яшьләр эшләре һәм спорт министры урынбасары Алмаз Минегулов, Чаллы политехника институты профессоры, проректор Әскәр Хәйруллин, В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты ректоры Асия Тимирясова, бихисап сәнгатькәрләр һәм башкалар… Кайларда гына торсалар да, кайсы өлкәдә хезмәт куйсалар да, үзләренең туган якларын яратып, «Аксубаем – ак төбәгем», – ди минем якташларым. Әлеге очрашу кичәбез дә Аксубай районының гимны булган нәкъ шул җыр белән тәмамланды. Башкача мөмкин дә түгел, бар эштә дә өлгер, җитез якташларым, һәр көннән тәм табып, республикабызның алгарышына, киләчәгенә үз өлешләрен кертеп яшиләр.

Алия АБРАРОВА,
КФУ студенты.

«Җомга»

Шагыйрь Рәниф Шәриповның шул исемдәге шигырь китабын укып чыкканнан соң

Рәниф Шәрипов – поэма остасы һәм шул ук вакытта ул кыска шигырьләрне дә бик теләп иҗат итә. Аның әсәрләре вакытлы матбугатта бик еш басыла килә, китаплары да күп, менә әле Татарстан китап нәшриятында «яңа гына табадан төшкән» «Җомга» исемле китабы укучы кулына килеп иреште, шөкер. Бу китапка шагыйрьнең сигез поэмасы, шигырьләре, дүртьюллыклары тупланган.

Китапның атамасы әсирлекне дә, совет зинданын да күргән Закир абзый язмышыннан алынган. Закир абый нинди генә җәфаларга дучар булмасын, ул – денен, Ана телен, ватанын онытмаган батыр ир, нинди генә кыен шартларда калмасын, җомга көнне чиста кием киеп, олы бәйрәм ясый торган булган. Җомга ул – чисталык, рухи сафлык дигән сүз. Закир абзыйны әнә шул «Җомга» алып чыга бәлаләрдән.

Китап гомумән кешенең һәм рухи, һәм бәдәни сафлыгы турында. Шул ук вакытта Рәнифнең бу китабы сагыну, юксыну һәм җирсү хисләре турында да. Социаль гаделсезлек, халык малын талаучыларның миһербансызлыгы турында да, саф сөю – мәхәббәт турында да.

Әсәрләрдә хәрәкәт итүче каһарманнарның сызланулары, кичерешләре китапның буеннан-буена кызыл җеп булып тартылган.

Юксыну хисе ул – якыныңны кыска вакытка гына югалтып тору хисе. Сагыну хисе исә озак вакытларга аерылып торудан хасил була. Ә җирсү хисе түзеп тора алмаслык сагынудан килә. Җирсү Ватаныңа кайта алмаудан, туганнарыңны бик озак күрә алмаудан ярала. Ватаныннан сөрелгән халыкларның юксынуы – сагынуга, сагынуы җирсүгә әверелә. Җирсү хисеннән кеше акылдан язарга да мөмкин. Закир абзый да, Акбүре дә һәм башка каһарманнар да фаҗигале дә, әче ләззәтле дә җирсү хисенә уралганнар. Шул ук вакытта җирсү бу шигырьләрне иҗат итүче Рәнифне дә чорнап алган. Табигый ки, җирсү хисе бу китапны укучыга да йогачак. Ул – шанлы узганыбызга җирсү, бетә бара торган авылга, юкка чыга барган йолаларыбызга сызлану, табигатьнең фәкыйрьләнүенә, Кыйбла чишмәләренең юкка чыгуына ярсып үкенүдән барлыкка килгән тойгылар.

* Иданне түгел, җанымны,
Җырларымны таптыйлар
* Сала-сала өен.
Сүгә-сүгә һаман
Көйсез татар көен.
Исләренә төшәр
Вафирә дә Хәйдәр.
Үкенечле еллар.
Аянычлы хәлләр.
* Байлар байлык җыя
Татар моңын сатып.
* Күпме алар сукыр тәрзәле
Җансыз, ямьсез, үле авыллар!

«Биш алма» әсәрендә авылдан китеп баручы шагыйрьгә сабый кыз биш алма бүләк итәр өчен каһарманның артыннан йөгерә. Рәниф яза:

Күкрәгенә биш алмасын
кыскан.
Көзге җилдә ябык гәүдәсе.
Ул йөгерә,
тик артыннан куа
Замананың кара шәүләсе.

Бу – символ, кыз артыннан авылны, йолаларны, кызны бетерер өчен кара шәүлә йөгерә. Кара шәүлә инде авылларны йотып бетерә бара: Русиядә соңгы елларда 15 мең авыл, 13тән артык халык (милләт) юкка чыккан. Татарстанда йөздән артык татар мәктәбе ябылган. «Коткарыгыз!» дип, хет урамга чыгып кычкыр!

Акбүре – татар халкының мифик анасы, табигать сакчысы. Рәнифнең әсәрендә Акбүре капкынга эләгә, аңа качу юк, аны күктәге Каракош сагалый, урман эче тулы аучылар:

Аңлый Бүре: азатлыкның
Бүген иң соңгы көне.

Монда да киная, символ бар. Әнә шул кинаяләр, ишарәләр, астарлы сүзләр Рәниф Шәриповның иҗатын кызыклы итә дә инде.

Рәниф Шәриповка – 66 яшь. Түгәрәк санмы бу? Әлбәттә, түгәрәк сан. Һәм серле-могҗизалы сан. «66»ның соңгы «6»сын «9»га борып куйсаң, Рәнифкә 69 яшь булыр иде. Беренче «6»сын борып куйсаң, Рәнифкә 96 яшь булыр иде. Икесен дә борып куйсаң Рәнифкә 99 яшь булыр иде. Мин, әлбәттә, Рәнифнең 100 яшькә җитүен һәм шулай актив иҗат итүен телим! Йөз яшә, дустым Рәниф!

Рабит БАТУЛЛА.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Казаным

Яңа ел каникулларын үзебез дә, балалар да бик көтеп алдык, чөнки гаилә белән бергәләп кая да булса бару, ял итү, күңел ачу мөмкинлеге бик сирәк эләгә. Ә бу елларда кунакка да барырга, шәһәрдәге төрле күңел ачу мәйданнарына да чыгарга, туганнар белән очрашырга да көннәр җитәрлек булды.

Шөкер, Казаныбыз елдан-ел гына түгел, көннән-көн матурлана. Башкалада җәен дә, кышын да гаилә белән чыгып ял итәр урыннар бик күп. Җәй көне яңа ачылган яки төзекләндерелгән паркларда рәхәтләнәбез. Балаларның күңелен күрим дигән әти-әниләргә бөтен мөмкинлекләр дә бар. Кремль яр буе да халыкның иң яраткан урыннарының берсенә әверелде. Анда җәен дә, кышын да бик рәхәт. Башка шәһәрләрдән кунакка килгән туганнарыбызга күрсәтер урыннарыбыз да күп, шөкер.

Кыскасы, Казаныбыз бик матур. Шуның кадерен генә белсәк иде.

Гөлия АБДУЛЛИНА,
Казан.

Иске елдан – яңа бүләк

Декабрь азагында тантаналы рәвештә Әмәт паркы ачылды. Балалар бик сөенде, әкияттән персонажлар, кар кызлары килсен дә, ничек куанмыйсың ди инде.

Паркта спорт базасы урнашкан. Биредә прокатка чаңгы, чана алырга була, хәтта янәшәдә җылы киемнәр сатыла торган кибет тә эшли. Шарфыңны, бияләеңне өйдә онытып калдыргансың икән, анысы да бик кулай. Тамак ялгап алырга сәүдә нокталары эшләп тора. Сәламәтлекне ныгытыйм дисәң, саф һавада күбрәк булырга кирәк шул. Парк көне-төне компьютерга табынып утырган балаларны күбрәк җәлеп итсен иде. Киләчәктә экология дәресләре, төрле ярышлар, очрашу-кичәләр дә, концертлар да уздырылыр әле монда.

Равилә МӨБАРӘКШИНА,
Казан.

Америка Кушма Штатлары Президенты итеп Трамп сайланганнан соң, аның турында журналистлар нәрсә генә язмады.

Бәрәңгедән аермасын

Трамп үзенә кирәк нәрсәне бер капчык бәрәңгегә сатып алырга да булдыра, дигән сүзләр аеруча күңелемә кереп калды. Хикмәтле бит безнең бәрәңге. Без кечкенә чакта аның биш алты яфрагы күренүгә үк өзеп, ашка сала башлый идек. Сугыштан соңгы елларда да безне ул гына коткарып калды. Бакчабыздан ел саен 600 пот бәрәңге ала идек. Татарстанның иң бай хатын-кыз эшмәкәрләренең берсе – «Бәхетле» кибете хуҗасы Мөслимә ханым да бизнесын бабасының бәрәңге бакчасыннан башлаган дип укыган идем. Кыскасы, гади халыкка да, Президентка да бәрәңге якын. Ходай аннан аермасын.

Рәис ИДРИСОВ,
Казан.

Ишегалдына керерлек түгел

Казан кайдадыр көньякта урнашкан кала булса, кыш айларын да җырлап кына чыккан булыр идек тә, нишлисең, өлешеңә тигән көмешең, берни эшләп булмый.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Кар яуса, бигрәк тә безнең Азинодагы Новоселье, Тыныч урамнарындагы йортлар тирәсендә эшләр мөшкелгә әйләнә. Андагы карны шәһәрдән читкә чыгару турында уйлаган кеше дә юк, ахры. Җитмәсә ишегалды машина утарын хәтерләтә. Балконга чыгып юри генә санаганым да булды шуларны. Йөзләгән машина анда. Куярга урыны иркен булса бер хәл, ни алга, ни артка бара торган түгел. Балалар мәйданчыгын коймa урынына шушы машиналар әйләндереп алган. Йортларның шәхси хуҗалыклар белән чикләнә торган ягы тар гына тыкрыкны хәтерләтә. Такси шоферлары бу тирәгә килмәскә ничәмә-ничә кат тәүбә иткәндер инде. Узып барышлый ике минут та туктап тора алмыйсың монда, артыңнан алты-җиде машина кычкырта башлый. Дөнья булгач, «Ашыгыч ярдәм» машинасы да килми тормый. Юкса, йортны төзегәнче, бу проектлар бик күп акыллы башлар кулыннан уза бит, алар ни карый да ни уйлый икән?

Әминә ИСМӘГЫЙЛЕВА,
Казан.

Кая бара бу дөнья?

Ниндидер заман чире калкып чыкты – балалар үз-үзләренә кул сала. Бу, берсүзсез, барыбызны да кайгыга сала. Нигә күбәеп китте соң әле мондый гамәлләр? Элек тә булганмы ул мордарлык?

Беренче карашка, хәзерге заманда мондый гөнаһлы эшләр кылынмаска да тиеш кебек: тамак – тук, өс – бөтен. Тикшереп карасаң, андый балаларның күбесе җитеш гаиләләрдә тәрбияләнгән була. Тормышка яраклашмаган, чебен тимәс чер итәр, бер сүз дә күтәрә алмый торган балалар бәлкем артык җитеш, матди байлыклар рухи кыйммәтләрдән өстен куелган гаиләләрдә үсәдер?

Уйлап карыйк әле, бүген ничек тәрбияләнә соң безнең балаларыбыз? Без түгел, компьютер, чәчләрне үрә торгызырлык кинофильмнар тәрбияли хәзер аларны. Телевизор экранына һәрбер тапшыру алдыннан «6, 12, 16 яшьтән карарга ярый» дигән язу элеп кенә котылып булмый моннан. Кешенең, бигрәк тә баланың психологиясенә куркыныч, үтергеч йогынты ясый торган тапшыруларны бөтенләй алып ташларга кирәктер. Икенчедән, балаларга беренче сыйныфтан ук психология дәресләре кертеп, ихтыяр көчләрен ныгытсак та, начар булмас иде.

Балалар белән андыймондый фаҗигале хәл килеп чыкса (берүк инде, Алла сакласын!), беренче чиратта укытучыларны һәм әти-әниләрне гаепли башлыйлар. Әйе, баланың исәнлеге, гомере өчен ата-аналар да, укытучылар да җаваплы. Ләкин әти-әниләрнең барысы да Макаренко түгел бит, укытучының да законлы эш көне бар, аны өйдә үз гаиләсе дә көтә. Шуңа да бөтен гаепне укытучы белән ата-анага гына кайтарып калдыру һич тә дөрес түгел дип саныйм.

Хәзерге заман балалары бигрәк сыек инде: сүз дә әйтмә син аларга, тырнак белән дә чиртмә. Әгәр дә бала гаепле һәм тел белән генә әйткәнне аңламый икән, азмы-күпме җәзасын да алырга тиештер. Җәзасыз калу яңа җинаять тудыра, диләр бит. Гамәлен күрә җәза динебез буенча да кире кагылмаган. Хәлфәләрнең янында да сыек тал чыбыгы белән савытка салынган борчак торган, дип аңлаталар иде безгә.

Болай барса, умыртка баганалары сыек, рухлары сынык, сүз күтәрмәс, тормышның кадерен белмәс эгоистлар буыны үстерербез. Әгәр дә укытучыларны, юк-бар гаеп табып, прокуратура юлында йөртә башласалар, мөгаллим булырга теләүчеләр саны да бик нык кимер. Аларның дәрәҗәләре болай да бик нык төште. Элек балалар өчен укытучы сүзе әти-әнинекеннән дә өстен иде. Ә хәзер?..

Данияр ГЫЙЛЬМАНОВ,
Яшел Үзән районы,
Урысбага авылы.

Очрашулар гомерне озайта

Соңгы елларда тормышыбызны очрашулар белән бизәү матур бер гадәткә керде: сыйныфташлар, төркемдәшләр очрашуы. Аларда ерак калган яшьлегеңә кайткандай буласың, яшәү дәртең артканын тоясың. Күптән түгел генә бу хисләрне кабат кичерергә туры килде безгә. Яңа Тинчәле авылында туып-үскән, бүген зур шәхесләр булып җитешкән авылдашлар бергә җыелдык.

Бай тарихлы Яңа Тинчәлебез элек-электән зыялы, мәчетле, мәдрәсәле авыл булып тирә-якта дан тоткан. Туган авылыбызда Рәсәйдә өченче (Касыйм белән Кырымнан кала), ә Татарстанда беренче указлы мәчет салынган. Аларда атаклы Бикколовлар нәселе мулла булып торган. Алдынгы карашлы Касыйм Бикколов татар әдәбиятына беренче тарихи роман язган язучы буларак та кереп калган. Бу изге нәселнең ике улы: Ибраһим һәм Касыйм Бикколовлар турында «Шәхесләребез» сериясендә мәгълүматларга бай саллы гына китап та дөнья күрде. Узган елның апрелендә аны тәкъдим итү кичәсе авылыбызда һәм район үзәгендә бик зурлап уздырылган иде. Бәйрәмгә кайткан танылган язучылар, галимнәр чал тарихлы авылыбызның матур тормышына, аның кешеләренә ихластан сокландылар.

Башкалабызда мул табын артында узган авылдашлар очрашуы да әлеге китапны тәкъдим итүнең дәвамы шикеллерәк булды. Бу изге эшнең башында торган, китапны дөньяга чыгаруда башлап йөргән, матди ярдәм күрсәткән авылдашыбыз – Татарстан Республикасы финанс министры Радик Гайзатуллин әлеге очрашуны шул шатлыклы вакыйганы искә төшереп башлап җибәрде. Тантананың башында ук әлеге китапны төзүче, язучы, авылыбыздан чыккан бердәнбер профессор Флюра Хәсәнова-Сәйфуллина чыгыш ясады. Аңа шактый тырышырга, архивларда утырырга, һәр мәгълүматны җентекләп җыярга туры килгән. Кунакларның барысы да ил-көн алдында дәрәҗәле кешеләр. Татарстан Дәүләт Советы депутаты Ринат Гайзатуллин, «Позис» заводы директоры Радик Хәсәнов, Горький исемендәге заводтан сыйныфташым Фердинанд Хөснетдинов, шулай ук җитәкче Фоат Садретдинов, авылыбыз кияве, район администрациясе башлыгы урынбасары Сәлим Даутовлар адресына очрашу барышында рәхмәт сүзләре күп ишетелде. Аларның барысы да 330 еллык тарихы булган авыл халкы матур яшәсен өчен, кулларыннан килгән кадәр ярдәм күрсәтеп, тырышып йөрүчеләр. Авылыбызның балкып торган мәктәп, клуб биналары, мәчетләре, күперләре, көзге кебек асфальт юллары – Радик Рәүф улы җитәкчелегендәге шушы мәрхәмәтле авылдашларның игелекле ярдәме нәтиҗәсе. Инде күп кенә авылларда Сабан туйлары да үткәрелми башлаган бер заманда, безгә ел саен бөтен тирәяк авылларны җыеп, мәйдан гөрли.

Әлеге тарихи очрашуга авылыбызда төпләнеп, туган нигезләрен таркатмыйча, шунда көн итүче авылдашларыбыз да килгән иде. Яңа Тинчәле авылы җирле идарәсе башлыгы Мансур Төхфәтуллов, мәктәп директоры Гөлгенә Гайзатуллина, уенын-чынын бергә кушып, авылыбызның мәдәният министры дип йөртелүче, үзе гармунчы, үзе җырчы Интал Шәйхаттаров туган яктан күп сәламнәр алып килгәннәр. Очрашуның тагын бер ягын әйтми кала алмыйм, бәйрәмгә авылдашлар парлап чакырылган иде. Гаиләләр ныклыгын арттыру турында илкүләм сүз барганда, монысы да кечкенә нәрсә түгел. Тинчәлебезнең кияүләре дә тел-теш тидерерлек түгел. Татарстан Дәүләт тикшерү комитетының җитәкче урынбасары Руслан Җәләлиев, «Татарстан ашлык технологияләре» генераль директоры Сирин Шәрапов изге җирдә туып-үскән кызларга лаек булырга тырышып яшиләр, эшлиләр. Сөйгән ярларын үстереп биргән авылга алар да рәхмәтле.

Бик мәгънәле очрашу булды ул. Зур уңышларга ирешкән авылдашларыбызны котларга да җай чыкты. Мәктәбебез директоры Нияз Фәизовның кызлары Чулпан белән Гөлнурны «Фидакарь хезмәт өчен» медале, юрист кыз Рузинә Фәтхуллинаны үткән юбилее белән тәбрикләдек.

Без, авылдашлар, әлеге очрашуда нәкъ менә Яңа Тинчәледә тудырганы өчен, Ходайга рәхмәт укып утырдык, бүгенге заманда кайбер авылларның гомерләре кыл өстендә генә эленеп торганда, үзебезнең шундый бай тарихлы, зыялы, «җиде йөз тинчәл» дип аталып йөртелгән туган авылыбызның гомерен озайтасы килү теләге дә туды. Бүгенге көндә урта мәктәптә 41 бала белем алуын, 11нче сыйныфта бер генә бала булуын белеп бераз борчылсак та, беренче сыйныфка ике бала киләсен ишетеп шатланып куйдык. Бергә генә булса да, укучылар артачак бит! Мәктәптәге балалар санын арттыруның тагын бер юлын беләм мин. Ятим калган балаларны гаиләләргә алып тәрбияләү. Татарстанда мондый матур үрнәкле авыллар бар инде. Безнең Яңа Тинчәлебезнең игелекле, тырыш шәфкатьле халкы да шундыйларга кушылса, туган авылыбызның киләчәге тагын да өметле булыр.

Бүген чәчләребезгә чал керсә дә, барыбыз да кайчандыр укучы балалар булганбыз бит. Шуңа да мәктәп елларыбызны искә төшереп, тирән белем биргәннәре өчен, укытучыларыбызга олы рәхмәтләр әйтеп утырдык. Чынлап та, алтын бәһасе олы шәхесләр иде алар. Исәннәренә Ходай озын гомер бирсен, үлгәннәренең урыннары җәннәттә булсын!

Очрашуның күңелле мизгелләрен мәңгеләштереп, фотоаппарат күзләрен челт-челт йомып кына торды. «Россия 1 – Татарстан» каналы хәбәрчесе, шулай ук авылдашым, сыйныфташым Фәннур Хәсәнов бу очрашуны фильм итеп ясарга вәгъдә бирде. Сүзендә тора торган егет ул.

Очрашу һәркемнең күңел кылларын тибрәтерлек ихлас булды. Күз яшьләреннән дә оялмадык. Мондый тәэсирле күрешүнең беренчесе булса да, соңгысы булмасын дип, зур өметләр, якты хыяллар белән таралыштык.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

ЧАЙНВОРД

«Спорт төрләре»



Нияз Бишбалта төзеде

1. Гимнастика һәм цирк сәнгатенең бер төре.
2. Ритмлы музыка белән башкарыла торган физик аэроб күнегүләр.
3. Биек тау түбәләренә менү спорты.
4. Махсус юлсыз җирдә йөри торган «тау велосипеды» спорты.
5. Көрәшнең бер төре (махсус шлем, перчатка белән; аяк, кул белән сугарга ярый).
6. Кечкенә тупчыкны махсус кәшәкә белән сугып, оягa кертү спорты.
7. Ике кара-каршы команданың бер-берсенең капкасына мөмкин кадәр күбрәк туп тибеп кертүдән гыйбарәт спорт уены.
8. Ике команданың махсус кәшәкә (стик) белән резин тупны көндәшләр капкасына кертү спорт уены.
9. Ике уенчының ракетка һәм каты тупчык белән биналар эчендә уйнала торган спорт төре.
10. Ак һәм кара төстәге 64 шакмакны аралаштырып буялган тактадан һәм 16шар ак һәм кара төстәге төрле формадагы фигуралардан торган спорт уены төре.
11. Махсус тупчыкны ятьмәле бау өстеннән бер-берeңә чәпәмә-ракетка белән бәрешеп, шул тупны җиргә, ятьмәгә тидермәү шарты белән уйнала торган парлы уен.
12. Махсус снарядта (чаңгыда) карлы таудан шуып төшү спорты.
13. Махсус кием белән су астында йөзү спорты.
14. Сәламәтлекне ныгытуга, организмны чыныктыруга ярдәм итүче физик күнегүләр системасы.
15. Ике спортчы арасында кул көрәштерү спорты.
16. Спорт ярышы төре (спортчы йөзеп, велосипедта узышып, аннары йөгереп, кыска вакыт арасында иң яхшы күрсәткечкә ирешергә омтыла).
17. Бильярдка охшаган латыш милли спорт уены.
18. Стендка ату төренә охшаган, тәлинкәләргә ату спорты.
19. Халыкара интеллектуаль өстәл уены (борынгы Кытайда уйлап табылган).

Җаваплар. **1.**Акробатика **2.**Аэробика **3.**Альпинизм **4.**Маутинбайк **5.**Кикбоксинг **6.**Гольф **7.**Футбол **8.**Лякросс **9.**Сквош **10.**Шахмат **11.**Теннис **12.**Сноуборд **13.**Дайвинг **14.**Гимнастика **15.**Армспорт **16.**Триатлон **17.**Новус **18.**Спортинг **19.**Го.

Бөтен кызыклы мәгълүмат бер урында
www.shahrikazan.com

Бер кулында – каләм, икенчесендә мылтык булган аның

Казанның республика балалар китапханәсендә төрле әдәби-музыкаль чаралар даими үткәрелеп тора. Шуларның чираттагысы фронтовик-шагыйрь Шамил Гәрәйгә багышланган иде. Бу кичә Яңа Савин районының «Иркенлек» балалар һәм яшүсмерләр ял һәм туристлык үзәге хезмәткәрләре белән берлектә узды.

Үзәк белгече Фәридә Сәлимова сөйләвенчә, Шамил Гәрәй шагыйрь генә түгел, ул үзен тәрҗемә эшендә дә сынап караган. Барто шигырьләрен, Лермонтов, Чехов әсәрләрен татарчага тәрҗемә итеп, бастырып чыгарган. Бөек Ватан сугышы башлануга, беренче көннәрдән үк фронтка китә шагыйрь. Бер кулында – мылтык, икенчесендә каләм була аның. Сугыш елларында язылган шигырьләрен фронт газеталарында бастыра.

Кече командир Шамил Гәрәй Мәскәү янындагы рәхимсез сугышларның берсендә чолганышта калып, контузия ала, фашистлар кулына әсирлеккә эләгә. Биш елга сузылган тоткынлык чоры эзсез узмый. Шагыйрь 1946 елны Польшада госпитальдә вафат була. Аны Польша хәрбиләр зиратына җирлиләр.

Фәридә ханымның шагыйрь турында сөйләгәннәрен балалар йотлыгып, тын да алмый тыңлап утырды. 18нче музыка мәктәбеннән Диләрә Галимова, Лилия Әхмәдиева башкаруындагы җырлар кичәгә ямь өстәде. Укучылары Шамил Гәрәйнең шигырьләрен дә укыдылар. «Иркенлек» туристлык үзәге директоры Рафаэль Фазлыев, эзтабар-язучы Шаһинур Мостафинның чыгышлары очрашуны тагын да гамьле итте. Тарихи шәхесләребезне үзебездән соңгы буынга тапшыра алуыбыз сөенечле хәл.

Равилә МӨБАРӘКШИНА,
Казан.

«Татспиртпром» су һәм соклар чыгарачак

Компания елны уңышлы тәмамлап, киләчәккә зур планнар кора.

«Татспиртпром» Мамадыштагы филиалы базасында эчәргә яраклы су чыгара башларга ниятли. Шулай ук төрле соклар һәм сыра җитештерү проектлары тикшерелә. «Татспиртпром» АҖ генераль директоры Ирек Миңнәхмәтов әнә шулай дип белдерде. Компания социаль проектлар белән дә шөгыльләнә. Шуларның берсе – «Казан» халыкара ат-спорт комплексын үстерү. 2016 елда бирегә бергә-бер көрәш мәйданчыгы һәм футбол кыры булдырылды. Киләчәктә теннис, гольф мәйданчыклары, пейнтбол клубы ачу күздә тотыла. Росстат мәгълүматларына караганда, «Татспиртпром» елны Россиядә тармак лидеры статусын саклаган хәлдә тәмамлый. «Татспиртпром» АҖ директорлар советы рәисе Илдар Халиков 2016 елның 24 октябрендә компанияне «Татарстанда иккенче салым түләүче» дип атады. 2016 елда компания 12,3 миллион декалитрдан артык продукция җитештерде. «Татспиртпром» брендлары илнең әйдәп баручы сәүдә челтәрләрендә сатыла. Росстат мәгълүматларыннан күренгәнчә, беренче тапкыр Россиядә сату күләмнәре Татарстандагыдан да артып китте. Компания «Арыш мае» челтәрен актив рәвештә үстерә. Казанның Сәлимҗанов урамы, 17 йорт адресы буенча урнашкан кибет-музеенда 9 меңнән артык турист булган. Компания товар ассортиментын елдан-ел киңәйтә, сатып алучыларга хезмәт күрсәтү сыйфаты арта, барлык кибетләрдә дә яңа касса җиһазлары урнаштырылган, аларның һәммәсе дә ЕГАИСка тоташтырылган.

Реклама

КАЗАНСКИЙ ЗАВОД СИЛИКАТНЫХ СТЕНОВЫХ МАТЕРИАЛОВ
КИРПИЧ от 8,87 р./шт.
5-707-909
5-719-259
www.kzssm.ru
подробности по телефону
ГАЗОБЕТОН от 57,60 р./шт.
ЖБИ изделия
ОТГРУЗКА КРУГЛОСУТОЧНО
Реклама

АФИША
16 – 22 ГЫЙНВАР

КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ
(ТАТАРСТАН УРАМЫ, 1)

16 гыйнвар «Легионер»
Туймазы Татар дәүләт драма театры
Башлана: **19.00**
Билет бәясе: **100-400 сум**

17 гыйнвар «Каеннарым белән» (Р.Миңнуллин, А.Бурина)
Туймазы Татар дәүләт драма театры
Башлана: **15.00**
Билет бәясе: **150 сум**

17 гыйнвар «Әрем исе» (И.Зәйниев)
Туймазы Татар дәүләт драма театры
Башлана: **19.00**
Билет бәясе: **100-400 сум**

18 гыйнвар «Каеннарым белән» (Р.Миңнуллин, А.Бурина)
Туймазы Татар дәүләт драма театры
Башлана: **15.00**
Билет бәясе: **150 сум**

18 гыйнвар «Тутиләр» (А.Коровкин)
Туймазы Татар дәүләт драма театры
Башлана: **19.00**
Билет бәясе: **100-400 сум**

20 гыйнвар «Мулла» (Т.Миңнуллин)
Башлана: **19.00**
Билет бәясе: **150-1000 сум**

21 гыйнвар «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин)
Башлана: **18.00**
Билет бәясе: **200-1200 сум**

22 гыйнвар «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин)
Башлана: **12.00**
Билет бәясе: **150-1000 сум**

22 гыйнвар «Ут күршеләр» (С.Юзеев)
Башлана: **12.00**
Билет бәясе: **150-1000 сум**

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ
(ГОРЬКИЙ УРАМЫ, 13)

17 гыйнвар «Мәхәббәт баскычы» (Ш.Фәрхетдинов, Р.Заһидуллин)
Башлана: **18.30**

18 гыйнвар «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин)
Башлана: **18.30**

19 гыйнвар «Ефәк баулы былбыл кош» (А.Гыйләҗев)
Башлана: **18.30**

21 гыйнвар «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин)
Башлана: **17.00**

22 гыйнвар «Бер күрешү – үзе бер гомер!» (Ф.Яруллин)
Башлана: **17.00**
Билет бәясе: **250-600 сум**

ТАТАР ДӘҮЛӘТ «ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

19 гыйнвар «Щелкунчик» (Э.Т.А.Гофман)
Башлана: **11.00, 13.00**

21 гыйнвар «Идет Коза рогатая» (М.Протасова)
Башлана: **10.00**

21 гыйнвар «Айболит» (К.Чуковский, Н.Егорова инсц.)
Башлана: **11.00, 13.00**

21 гыйнвар «Таңга – Чулпан, Айга – Зөһрә» (Зөлфәт)
Башлана: **15.00**

22 гыйнвар «Волшебник изумрудного города (А.Волков)
Башлана: **11.00, 13.00**
Билет бәясе: **200-300 сум**

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕ
(ПАВЛЮХИН УРАМЫ, 73)

20 гыйнвар «Казан кичләре»
«Мәйдан» каналына биш яшь тулуга багышланган интерактив чара
Башлана: **18.00**
Билет бәясе: **400-1200 сум**

«КАЗАН ЯРМИНКӘСЕ»
(ОРЕНБУРГ ТРАКТЫ, 8, 1НЧЕ ПАВИЛЬОН)

22 гыйнвар Бөтенроссия этләр күргәзмәсе
Башлана: **10.00**
Билет бәясе: олыларга — **150,** балаларга һәм пенсионерларга **100 сум**

Кайсы гына чорда булмасын, безнең халык гармун моңнарыннан аерылмаган. Гармунда уйнарга хыялланмаган ир бала булдымы икән?! Апас районының Әлмәндәр авылында Гыймадиевлар гаиләсендә өч малай да гармунчы була. Берсе скрипкада оста уйный. Җиде яшьлек Азат үзләрендә яшәгән ике туган абыйсы Шәйхетдиннең карават астына яшергән гармунын үзе югында алып шыңгырдата башлый. «Шахта», «Эрбет» кебек халык җырларын уйнарга өйрәнә.

Моңлы архитектор

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

Сигез яшендә Апаста узган бәйгедә II урын алып кайта. 1942 елда Казанда үткән Республика конкурсында Азат II урынга лаек була. Шул чагында күренекле композитор Салих Сәйдәшев малайга гармун бүләк итеп, аның кулын кыса. Азатка туган тиешле, Камал театрында эшләп алган артист Салих Идрисов белән дә дус була композитор. Бүләк ителгән гармун малайга ошап бетми, ул башкача эшләнгән булып чыга. Туганнарына кайткач гармун тартып утырганда, аларга Салих Сәйдәшев килеп керә. Малай әлеге уен коралында уйнау җайсыз булуын әйткәч, ул аны базарга алып барып сатарга һәм башканы алырга тәкъдим итә. Икенче көнне композитор үзе дә алар белән бергә китә. Азат бер тальянны кулына алып сыздырып җибәрүгә, тирә-юньдәге сатучылар аның янына җыелышла. Бүләк гармунын саталар да, әнә шул тальянны алалар. Бертуган абыйсы белән авылга кайтканда да юл буе гармунда уйный Азат. Кич җиткәнен түземсезлек белән көтә: гармуны белән мактанасы килә бит! Ә инде кич белән тальянын сузып җибәрүгә, Әлмәндәрнең бөтен яшьләре аларның капка төбенә җыела. Авыл моңга күмелә.

Фронтка китүче авылдашларын да гармун белән озата егет. 1944 елда, 17се тулмаган килеш, үзен дә фронтка җибәрәләр. Энзадигән станциядә аларны танк йөртергә дә, артиллериядән, пулеметтан атарга да өйрәтәләр. Мәскәүдә киемнәрен алыштырып поезд белән китеп барганда, фашист самолетлары аларны бомбага тота башлый. Урман эченә кергәч, поездны туктатып, 330 чакрым чамасы җәяүләп китәргә мәҗбүр була солдатлар. Азат Гыймадиев каты гына яраланып, госпитальдә дә ятып чыга.

Фронт юлларын узып, демобилизацияләнеп кайткан егет туры консерваториягә китә. Салих Сәйдәшев сугышка киткәнче үк аңа шунда барырга киңәш иткән була. Тик язмышка буйсынып, төзелеш-архитектура институтына китә егет. Архитектор һөнәрен сайлавына үкенми Азат абый. Әлмәт, Алабуга, Менделеевск, Минзәлә, Чаллы шәһәрләрен проектлауда катнаша. Министрлар Советының төзелеш-архитектура идарәсендә, соңрак Мәдәният министрлыгында хезмәт куя. Петропавловск соборындагы планетарий да Азат Гыймадиев проекты буенча төзелгән. Әтисе урнәгендә олы кызы Гүзәл белән оныгы Карина да архитектор һөнәрен сайлаган. Казан Кремленең сәгатен, йолдызын куючыларның берсе дә әле Азат абый.

– Иң авыры әнә шул 1,5 тонналы йолдызны кую булды. Башта вертолет белән дә күтәртеп куеп карадык – барып чыкмады. Аннары трослар ярдәмендә тарттырып куярга туры килде. Соңыннан аны алтын белән дә капладык, – дип искә ала ул.

Кайда гына эшләмәсен, Азат абый гармуннан аерылмый. 20 ел буе Химиклар мәдәният сарае каршында эшләп килгән гармунчылар ансамблендә йөри. Өйләрендә дә җыр-моң тынып тормый. Азат абый баянын кулына алган саен, Лидия ханым аңа кушылып татар халык җырларын сузарга ярата. 65 ел әнә шулай моңга төренеп яши алар. Гаилә башлыгына берничә айдан 90 яшь тула дип һич уйламассың.

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.
ЧЫГАРЫЛЫШ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ – РАСИХА ГАБДЕЛБӘР кызы ИСМӘГЫЙЛОВА.
© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.
РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843). 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1551. Гомуми тираж – 6187.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 663. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор). 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843). 562-50-12,
факс: (843). 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы